**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Ш. Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш. Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«25» апрель 2025 ел** **№271**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алдан туктату турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 маддәсендәге 10 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 маддәсенең 6 нчы өлеше, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставының 49 маддәсенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф. Каюмовның шәхси гаризасы нигезендә, Әтнә район Советы карар чыгарды:

1. Каюмов Айрат Фәнил улының Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасыннан шәхси гаризасы нигезендә үз теләге белән азат итүне кабул итәргә.

2. Каюмов Айрат Фәнил улының Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен 2025 елның 25 апреленнән вакытыннан алдан туктатылган дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Әтнә муниципаль районының http://atnya.tatarstan.ru. рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе

Г.Г. Хәкимов